КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2023 ел, 5 октябрь

г.Казань

№ 1234

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында 6,5 км – 13 км участокта «Чаллы – Сарман» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегенең 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында 6,5 км – 13 км участокта «Чаллы – Сарман» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен юридик затлар милкендә (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре милекчесе) булган, кушымтада күрсәтелгән 36 242 кв.метр гомуми мәйданлы, «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте милкендәге (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре милекчесе) җир кишәрлекләрен (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Алына торган җир кишәрлекләрендә урнашкан 16:39:170101:247 кадастр номерлы «Юл транспорты корылмалары. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында 6,5 км – 13 км участокта Чаллы – Сарман автомобиль юлын реконструкцияләү» капиталь төзелеш объекты алынмый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районындагы Яңа Троицкий авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлекләре милекчесенә, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен түләү күләмен билгеләгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлекләре милекчесенә җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен акча түләүне;

алына торган җир кишәрлекләренә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган җир кишәрлеге милекчесе тарафыннан имза куелган килешү законнар белән билгеләнгән вакытта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъва бирүне.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 5 октябрь, 1234
нче карарына кушымта

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алынырга тиешле җир кишәрлекләре исемлеге

| Кадастр номеры | Урнашу урыны | Мәйданы, кв.метр | Милекчесе |
|---|---|---|---|
| 16:39:000000:3913 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Яңа Троицкий авыл җирлеге | 6 087 | «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте |
| 16:39:000000:4351 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Яңа Троицкий авыл җирлеге | 2 954 | «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте |
| 16:39:000000:4352 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Яңа Троицкий авыл җирлеге | 862 | «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте |
| 16:39:000000:4354 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Яңа Троицкий авыл җирлеге | 2 051 | «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте |
| 16:39:000000:4355 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Яңа Троицкий авыл җирлеге | 2 965 | «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте |
| 16:39:000000:4362 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Яңа Троицкий авыл җирлеге | 4 223 | «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте |
| 16:39:091502:295 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Яңа Троицкий авыл җирлеге | 8 225 | «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте |
| 16:39:091502:296 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Яңа Троицкий авыл җирлеге | 465 | «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте |
| 16:39:092001:726 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Яңа Троицкий авыл җирлеге | 2 610 | «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте |
| 16:39:092101:156 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Яңа Троицкий авыл җирлеге | 5 800 | «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте |
| Барлыгы | | 36 242 | |

_______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 5 октябрь, 1234
нче карарына кушымта

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алынырга тиешле җир кишәрлекләре исемлеге

| Кадастр номеры | Урнашу урыны | Мәйданы, кв.метр | Милекчесе |
|---|---|---|---|
| 16:39:000000:3913 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Яңа Троицкий авыл җирлеге | 6 087 | «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте |
| 16:39:000000:4351 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Яңа Троицкий авыл җирлеге | 2 954 | «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте |
| 16:39:000000:4352 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Яңа Троицкий авыл җирлеге | 862 | «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте |
| 16:39:000000:4354 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Яңа Троицкий авыл җирлеге | 2 051 | «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте |
| 16:39:000000:4355 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Яңа Троицкий авыл җирлеге | 2 965 | «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте |
| 16:39:000000:4362 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Яңа Троицкий авыл җирлеге | 4 223 | «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте |
| 16:39:091502:295 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Яңа Троицкий авыл җирлеге | 8 225 | «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте |
| 16:39:091502:296 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Яңа Троицкий авыл җирлеге | 465 | «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте |
| 16:39:092001:726 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Яңа Троицкий авыл җирлеге | 2 610 | «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте |
| 16:39:092101:156 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Яңа Троицкий авыл җирлеге | 5 800 | «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте |
| Барлыгы | | 36 242 | |

_______________________________